**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «10» октябреннән № 283

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 августындагы 865 номерлы һәм 2022 елның 15 сентябрендәге 1007 номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карары белән расланган «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә» нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карарына (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 271 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 1 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 таблица

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи окладның күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Оешма җитәкчесе | 19 862,0 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 15 279,0» |

III бүлектә:

5 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләү өчен өстәмәләр күләме - вазыйфаи окладка карата 0,3 %.

Дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен күрсәтелгән айлык өстәмә законнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт язуын рәсмиләштерү шарты белән даими нигездә дәүләт серен белгән хезмәткәрләргә түләнә.»;

IV бүлекнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Матди ярдәм авыру һәм дәвамлы дәвалану зарурлыгы, табигать бәла-казасы һәм башка нигезле сәбәпләр аркасында түләнә.

Матди ярдәм түләү шартлары һәм аның конкрет күләмнәре Учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә. Хезмәткәргә матди ярдәм күрсәтү турында карарларны Учреждение җитәкчесе кабул итә.»;

IV бүлекнең 5 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов